ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44, E-mail: archa@tatar.ru, www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«14» октябрь 2024 ел № 224

**«Муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына кергән инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидлар торагын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» 2017 елның 14 мартындагы 262 номерлы Башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында (04.12.2018 №1207, 13.05.2024 №321 үзгәрешләр белән)**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына кергән инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидлар торагын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» 2017 елның 14 мартындагы 262 номерлы Башкарма комитет карарына (04.12.2018 №1207, 13.05.2024 №321 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына кергән инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидлар торагын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.М. Хәсәновка йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
"__14__" __10__ 2024 ел, №__724
карарына кушымта

Муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына кергән инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидлар торагын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составы

| | |
|---|---|
| Галимуллин И.Ә. | - комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; |
| Хәсәнов И.М. | - комиссия секретаре, Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| *Комиссия әгъзалары:* | |
| Хафизов И.И. | - ТР Арча муниципаль районының Инвалидлар җәмгыяте рәисе , "Барыбыз өчен дә ачык дөнья" БИҖ эксперты; |
| Касыймов Р.Ф. | - Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Ибраһимова Д.М. | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Шәяхмәдова А.Р. | - Татарстан Республикасы буенча «Ватанны саклаучылар» МХОдә катнашучыларга ярдәм дәүләт фонды филиалы вәкиле, инвалидлар белән эшләү секторының социаль координаторы (килешү буенча); |

Идарәче компания яисә торак милекчеләре ширкәте вәкиле (килешү буенча).